**Дүртенче чакырылыш Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Азнакай шәһәр Советы**
**КАРАРЫ**

Азнакай шәһәре № 102-18 «12» октябрь 2022 ел

Азнакай муниципаль районы Азнакай шәһәр Советының 2014 елның 22 маендагы 126-38 номерлы «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы «Азнакай шәһәре» муниципаль берәмлеге чикләрендә янгын куркынычсызлыгының беренчел чаралары турында» карары белән расланган, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы «Азнакай шәһәре» муниципаль берәмлеге чикләрендә янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

2022 елның 14 июлендәге 276-ФЗ номерлы «Янгын куркынычсызлыгы таләпләре турында техник регламент» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» Федераль закон нигезендә,

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Азнакай шәһәре Советы

**карар итте:**

1. Азнакай муниципаль районы Азнакай шәһәр Советының 2014 елның 22 маендагы 126-38 номерлы «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы «Азнакай шәһәре» муниципаль берәмлеге чикләрендә янгын куркынычсызлыгының беренчел чаралары турында» карары белән расланган, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы «Азнакай шәһәре» муниципаль берәмлеге чикләрендә янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 1.4. пунктның  алтынчы абзацы үз көчен югалткан дип танырга;

2 өлешнең уникенче абзацында «Татарстан Республикасында җәмәгать тәртибен тәэмин итүдә гражданнарның катнашуы турында» 2005 елның 01 ноябрендәге 107-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы» сүзләрен «Җәмәгать тәртибен саклауда гражданнарның катнашуы турында» 2014елның 02 апрелендәге 44-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җәмәгать тәртибен саклауда гражданнарның катнашуы турында» 2015 елның 16 гыйнварындагы 4-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы» сүзләренә алмаштырырга;

2. Әлеге карарны  Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча бастырырга: http://pravo.tatarstan.ru. һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга: http://aznakayevo.tatar.ru.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны законлылык, хокук тәртибе, депутат этикасы һәм җирле үзидарә буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Рәис М. З. Шәйдуллин